**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения**

В соответствии с Правилами охоты, утвержденными приказом Министерства природных ресурсов и экологии Российской Федерации от 24 июля 2020 года № 477, **постановляю**:

1. Внести в параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения, определенные Указом Президента Республики Татарстан от 12 апреля 2013 года № УП-303 «Об определении параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 14 декабря 2013 года № УП-1216, от 12 июня 2014 года № УП-572, от 23 апреля 2015 года № УП-412, от 16 июля 2015 года № УП-654, от 15 августа 2015 года № УП-724, от 10 февраля 2016 года № УП-131, от 9 июля 2016 года № УП-588, от 7 июля 2017 года № УП-608, от 19 мая 2018 года № УП-381, от 30 мая 2018 года № УП-397, от 26 июля 2018 года № УП-541, от 19 февраля 2019 года № УП-130, от 24 мая 2019 года № УП-294, от 24 июня 2019 года № УП-361, от 23 мая 2020 года № УП-305, от 11 августа 2020 года № УП-473 и от 30 ноября 2020 года № УП-788), следующие изменения:

а) пункт 11 изложить в следующей редакции:

«11. Определить следующие сроки любительской и спортивной охоты:

на селезней уток с использованием живых подсадных (манных) уток – в весенне-летний период с первой субботы апреля по 6 мая;

на водоплавающую дичь – в весенне-летний период с третьей субботы апреля в течение 10 календарных дней;

на боровую дичь – в весенне-летний период с четвертой субботы апреля в течение 10 календарных дней;

на болотно-луговую дичь с подружейными собаками или ловчими птицами – в период с 25 июля по 5 декабря;

на боровую, степную и полевую дичь с подружейными собаками или ловчими птицами – в период с 5 августа по 5 января;

на водоплавающую дичь с подружейными собаками или ловчими птицами – в период с четвертой субботы августа по 5 декабря;

на водоплавающую, болотно-луговую, степную и полевую дичь – в период с первой субботы сентября по 5 декабря;

на боровую дичь – в период с первой субботы сентября по 5 января;

на волка – в период с 15 сентября по 28 (29) февраля;

на ондатру – в период с 1 октября по 28 (29) февраля;

на зайца-русака – в период с 15 октября по 10 января;

на норку, белку, енотовидную собаку, куницу, хоря – в период с 15 октября по 28 (29) февраля.»;

б) пункты 12, 13 и 14 признать утратившими силу.

2. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
28 декабря 2020 года
№ УП-889

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2020 елның 24 июлендәге 477 номерлы карары белән расланган Ау кагыйдәләре нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы, 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы, 2018 елның 30 маендагы ПУ-397 номерлы, 2018 елның 26 июлендәге ПУ-541 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге ПУ-130 номерлы, 2019 елның 24 маендагы ПУ-294 номерлы, 2019 елның 24 июнендәге ПУ-361 номерлы, 2020 елның 23 маендагы ПУ-305 номерлы, 2020 елның 11 августындагы ПУ-473 номерлы һәм 2020 елның 30 ноябрендәге 788 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Һәвәскәрләр һәм спорт авына түбәндәге сроклар билгеләргә:

тере алдавыч үрдәкләр ярдәмендә ата үрдәкләр аулау – язгы-җәйге ау чорында апрельнең беренче шимбәсеннән 6 майга кадәр;

су кошларын аулау – язгы-җәйге ау чорында апрельнең өченче шимбәсеннән 10 календарь көн дәвамында;

урман кошларын аулау – язгы-җәйге ау чорында апрельнең дүртенче шимбәсеннән 10 календарь көн дәвамында;

сазлык-болын кошларын этләр һәм ау кошлары белән аулау – 25 июльдән 5 декабрьгә кадәр;

урман, дала һәм кыр кошларын этләр һәм ау кошлары белән аулау – 5 августтан 5 гыйнварга кадәр;

су кошларын этләр һәм ау кошлары белән аулау – августның дүртенче шимбәсеннән 5 декабрьгә кадәр;

су, сазлык-болын, дала һәм кыр кошларын аулау – сентябрьнең беренче шимбәсеннән 5 декабрьгә кадәр;

урман кошларын аулау – сентябрьнең беренче шимбәсеннән 5 гыйнварга кадәр;

бүре аулау – 15 сентябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

су күсесе аулау – 1 октябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

соры куян аулау – 15 октябрьдән 10 гыйнварга кадәр;

чәшке, тиен, янутсыман эт, сусар, көзән аулау – 15 октябрьдән 28 (29) февральгә кадәр.»;

б) 12, 13 һәм 14 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 28 декабрь
№ ПУ-889